Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының унөченче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

22 июль, 2021 ел № 89

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлаулар беркетмәсен һәм 2021 елның 12 июлендәге гавами тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне исәпкә алып, **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен расларга.

2. Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен территориаль планлаштыру федераль дәүләт мәгълүмат системасының рәсми сайтында (https://fgistp.economy.gov.ru/) урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Питрәч муниципаль районының Кәвәл авыл жирлеге Советына «Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы «Кәвәл авыл жирлеге» муниципаль берәмлегенең жирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында» 2021 елның 19 маендагы 55 номерлы карарының элек кабул ителгән көчен югалткан дип танырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районының рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советының жирлекләрнең жирле үзидарә органнары белән үзара эшчәнлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламенты буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы башлыгы И.М. Кашапов